# Габдулла Тукай

Гомерендә - халкы язмышы, җырларында- халкы моңнары!



Татар халык шагыйре Габдулла Тукай (Габдулла Мөхәммәтгариф улы Тукаев) 1886 елның 14 апрелендә элекке Казан губернасы Мәңгәр волосте (ТАССР Арча районы) Кушлавыч авылында туа.

Кечкенәдән ятим калган Габдулла, кулдан-кулга йөреп, балачагын Сасна, Өчиле, Кырлай авылларында уздыра. Башлангыч белемне Кырлай авылы

мәдрәсәсендә ала.





- 1907 елның көзендә Тукай Казанга кайта. Ул үлемсез әсәрләренең күбесен шушында яза; профессиональ революционерлар даирәсенә керә; татар культурасының революцион-демократик канатын җитәкләүгә алына. Шагыйрьнең сугышчан шигърияте һәм иҗтимагый, әдәби процессларның иң четерекле проблемаларына багышланган публицистик чыгышлары әдәби-мәдәни хәрәкәтнең төп юнәлешен билгеләүче көчкә әверелә.

## Габдулла Тукай (1886-1913)



*Тукай исән.*
*«Җыры» күңелләрдә,*
*Яшәсәк тә үзен күрмичә.*
*Тукай килә моңлы сазын уйнап,*
*Шагыйрьләргә тынгы бирмичә.*

- Габдулла Тукай 1913 елның 15 апрелендә Казанда үпкә авыруыннан вафат була.





# Өчиледән Кырлайга китү вакыты



# Тукай дуслары белән

